СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы карары**

**22 март 2024 ел** **N 7**

**"Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Югары Бирәзә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 17 ноябрендә 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Югары Бирәзә авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге уставының 25 статьясына ярашлы рәвештә, Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Югары Бирәзә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендә 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Югары Бирәзә авылында гражданнар җыенының беренче этабын Югары Бирәзә авылы, Күпер урамы, 2 йорт адресы буенча 2024 елның 07 апрелендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Югары Бирәзә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендә 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Югары Бирәзә авылында гражданнар җыенының икенче этабын Югары Бирәзә авылы, Күпер урамы, 2 йорт адресы буенча 2024 елның 07 апрелендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

1 нче этап: Комсомол урамы,Бахчи – Сарай урамы, Күпер урамында яшәүчеләр.

2 нче этап: Пәшкәү урамы,Тарлау урамы,Ленин урамында яшәүчеләр.

4. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Югары Бирәзә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендә 8 номерлы карарында гражданнар җыены соравын яңа редакциядә бәян итәргә:

Сез 2024 елда Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 250 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналаынр, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Комсомол урамының 9 йортыннан 27 йортына кадәр – 350 метр урам-юл челтәренең юл өстендәге чокырларны ремонтлау)

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

5. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Югары Бирәзә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендә 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны ТР, Арча районы, Югары Бирәзә авылы,Күпер урамы, 2йорт адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan ru веб-адреслары буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Яңа Кырлай авыл
җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

СОВЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН1609012702